| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Бохар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Бохар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлегенең Бохар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

- Юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Урмышлы авылы, Центральная, 4, Яңа Елховой авылы, родничная, 22, Бохар авылы, Авангардная, 23 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф. Хәбибуллин